**СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр
авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

**«11» декабрь 2023 ел** **№131**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 февралендәге 61 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроле турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 февралендәге 61 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге» 3 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http:arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Ә.Ә.Гайфуллин

Яңа Кенәр авыл
җирлеге Советының
11.12.2023 ел, №131
карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Җирле үзидарә органына реклама тактасын килештерү турында гариза җибәрү факты булмаганда, автомобиль транспортын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтү буенча контрольдә тотылучы затның эшчәнлек башлаган көненнән алып 90 календарь көн узу.

2. Кварталда, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, шул ук вакыт аралыгында әлеге эшләрне башкару өчен билгеләнгән җыештыру һәм махсус техника санының кимемәве белән, объектларны һәм төзекләндерү элементларын җыештыру буенча эшләрне башкару бурычы йөкләнгән оешма хезмәткәрләре санының 50 һәм аннан да күбрәк процентка кимүе.

3. Ике календарь атна дәвамында, аннан алдагы чор белән чагыштырганда, хезмәт күрсәтү территориясендә объектларны һәм төзекләндерү элементларын җыештыру буенча эшләрне башкаруны үз бурычларына керткән оешманың хезмәт күрсәтү территориясендә травматология ярдәме сорап мөрәҗәгать иткән җәрәхәтләнү алган гражданнар санының 15 һәм аннан да күбрәк процентка артуы.

4. Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү ихтималы турында сөйли торган дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм гражданнардан, оешмалардан алынган һәм (яки) килгән мәгълүматларның дөреслеген бәяләүгә юнәлдерелгән чаралар нәтиҗәсендә аңа карата таләпләр муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән, төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре булган контроль объектының торышыннан тайпылуның 30 календарь көн эчендә өч һәм аннан да күбрәк очрагы ачыклану турында мәгълүмат булу.

5. Контрольдә тотылучы затка карата төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозган өчен административ хокук бозу турындагы эш буенча административ җәза билгеләү турында бер ел эчендә кимендә биш карар булу.

6. Ике календарь атна дәвамында, аннан алдагы чор белән чагыштырганда, торак пунктның бер административ-территориаль берәмлеге (урам, микрорайон) территориясендә җәрәхәтләнү алуга бәйле рәвештә травматология ярдәме күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән гражданнар санының 15 һәм аннан да күбрәк процентка артуы.